ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**13.09.2019** **№ 1546**

**Биектау муниципаль районы башкарма комитетының “Муниципаль контроль төрләре һәм аларны тормышка ашырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеге турында”, 2019 елның 15 августындагы 1306 номерлы карарын бетерү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 ел 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында”, 2008 ел, 26 нчы декабрь, 294-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы башкарма комитетының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, хокукый мониторинг нәтиҗәләре нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының “Муниципаль контроль төрләре һәм аларны тормышка ашырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеге турында”, 2019 елның 15 августындагы 1306 номерлы карарын бетерергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында” Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Афанасьев А.П.ка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын
Вакытлыча башкаручы Р.Р.Сабирҗанов

1 нче кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты
карары белән
______________2019 № ___

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә тормышка ашырыла торган муниципаль контроль төрләре исемлеген алып бару**
**Тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 ел 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы, “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында”, 2008 ел, 26 нчы декабрь, 294-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә эшләп чыгарылган һәм аларны тормышка ашырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль контроль төрләрен формалаштыру һәм алып бару вакытында килеп туа торган мөнәсәбәтләрне җайга сала (алга таба текст буенча – Исемлек).

1.2. Исемлекне формалаштыру һәм алып бару түбәндәге принциплар нигезендә тормышка ашырыла:

- Исемлеккә кертелергә тиешле муниципаль контроль төрләре турында мәгълүматларга таләпләрнең бердәйлеге;
- Исемлектә булган мәгълүматларның дөреслеге һәм вакытында актуальләштерелүе;
- Исемлектә булган мәгълүматларның ачыклыгы һәм һәркем алырга мөмкин булуы.

1.3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә аларны тормышка ашырырга вәкаләтле булган тормышка ашырыла торган муниципаль контроль төрләре турында мәгълүматларны Исемлеккә кертү өчен нигезләр булып, муниципаль контрольне тормышка ашыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен билгеләүче яки аны тормышка ашыру тәртибен һәм (яки) шартларын үзгәртүче норматив хокукый актлар тора.

1.4. Исемлек Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырыла.

## II. Исемлекнең структурасы, формалаштыру тәртибе һәм алып бару

2.1. Исемлеккә түбәндәге мәгълүматлар кертелә:

1) Биектау муниципаль районы территориясендә тормышка ашырыла торган муниципаль контроль төре атамасы;

2) билгеле муниципаль контроль төрен тормышка ашыру буенча вәкаләтләр йөкләнгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары исеме, аларның урнашкан урыны, телефоны;

3) муниципаль контрольне тормышка ашыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен билгеләүче Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актлар исеме һәм реквизитлары.

2.2. Исемлекне алып бару Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комититының икътисад бүлеге тарафыннан тормышка ашырыла (алга таба – Вәкаләтле орган).

2.3. Исемлектә булган мәгълүматларның актуаль халәттә булуын тәэмин итү буенча йөкләмәләр, билгеле муниципаль контроль төрен тормышка ашыручы вәкаләтле булган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына йөкләнелә (алга таба – Орган).

2.4. Исемлектә булган мәгълүматларның актуаль халәтен тәэмин итү максатыннан, Орган, билгеле муниципаль контроль төрен тормышка ашыруны билгеләүче (үзгәртүче) норматив-хокукый акт проектын килештерүгә җибәргән вакыттан бер эш көне дәвамында, Вәкаләтле органга язмача рәвештә мәгълүмат җиткерүне тәэмин итә.

2.5. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктларында күрсәтелгән хисап объектлары турында мәгълүматларны үзгәрткән вакытта, билгеле мәгълүматларны үзгәрткән көннән өч эш көне дәвамында Вәкаләтле органга Исемлеккә үзгәрешләр кертү турында, тәкъдим ителгән үзгәрешләрнең хокукый нигезләрен күрсәтеп, гариза җибәрә.

Гаризага административ регламентның, билгеле муниципаль контроль төрен тормышка ашыручы актуаль текстының электрон версиясе, Word форматында бер файлда беркетелә.

2.6. Вәкаләтле орган гариза алынган көннән өч эш көне дәвамында Исемлеккә билгеле үзгәрешләрне кертү турында норматив-хокукый акт әзерләүне тормышка ашыра.

2.7. Әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында күрсәтелгән норматив-хокукый акт үзенең законлы көченә кергәннән соң, Вәкаләтле орган яңартылган Исемлекне Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру өчен җибәрә.

2.8. Муниципаль контрольне тормышка ашыру Орган, муниципаль контрольне тормышка ашыру күздә тотылган федераль законны (башка норматив-хокукый актны) үз көчен югалткан дип танылган көннән башлап өч эш көне дәвамында бу хакта Вәкаләтле органга язма рәвештә хәбәрнамә бирә.

2.9. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 2.8 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамә алынган көннән соң өч эш көне дәвамында, Исемлеккә билгеле үзгәрешләрне кертү турында, хисап объектын Исемлектән чыгару максаты белән норматив-хокукый акт әзерләүне тормышка ашыра.

2 кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты
карары белән
______________2019 № ___

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә тормышка ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аларны тормышка ашырырга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге**

| № т/б | Муниципаль контроль төре атамасы | Муниципаль контрольне тормышка ашырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органы исеме (урнашкан урыны, телефоны) | Муниципаль контрольне тормышка ашыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен урнаштыручы Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актларның исеме һәм реквизитлары |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Муниципаль җир контроле | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы (Биектау авылы, Полковая ур., 9 нчы йорт. тел. 8(919) 684-54-43) | - Россия Федерациясе Җир кодексы;<br>- “Административ хокук бозулар турында” Россия Федерациясе Кодексы;<br>- “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 ел 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында”, 2008 ел, 26 нчы декабрь, 294-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләт җир күзәтчелеген гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органнарының муниципаль җир контролен гамәлгә ашыручы органнар белән үзара хезмәттәшлеге кагыйдәләрен раслау турында”, 2014 ел, 26 нчы декабрь, 1515 номерлы карары;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | турында", 2017 ел, 10 нчы февраль, 166 номерлы карары;<br>- "Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турында", 2015 ел, 13 нче октябрь, 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>- "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында", 2004 ел, 28 нче июль, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2015 ел, 21 нче июль, 7 номерлы карары белән кабул ителгән, "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы;<br>- Биектау муниципаль районы Советының 2005 ел, 29 нчы декабрь, 30 номерлы карары белән расланган, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә;<br>- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2005 ел, 29 нчы декабрь, 32 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында Нигезләмә;<br>- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2017 ел, 30 нчы март, 132 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмә;<br>- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 ел, 24 нче апрель 902 номерлы Карары белән расланган, авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан җир мөнәсәбәтләре объектларына карата Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен тормышка ашыру буенча функцияләрне башкару администартив регламенты |
| 2 | Муниципаль торак контроле | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенең торакны исәпкә алу һәм бүлү секторы | - "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында", 2008 ел, 26 нчы декабрь, 294-ФЗ номерлы Федераль закон; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | (Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Кооперативная ур., 5 нче йорт. тел. 8(84365)2-30-82 | - “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 ел 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында” Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгы боерыгы<br>- “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 ел, 28 нче июль, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;<br>- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2015 ел, 21 нче июль, 7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы;<br>- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2017 ел, 30 нчы март, 131 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмә;<br>-Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 ел, 22 нче февраль, 501 номерлы Карары белән расланган, “ Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен тормышка ашыру турында” муниципаль функцияне башкару административ регламенты; |

3 кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты
карары белән
______________2019 № ___

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә тормышка ашырыла торган муниципаль контрольне тормышка ашыру күрсәткечләре нәтиҗәлелеге**
**Исемлеге**

Күрсәткечләр:

1. *еллык күрсәткеч*: **узган елга карата, муниципаль контрольне тормышка ашырганда профилактика чараларының саны арту,%.**

V= A/B x 100 %
A – агымдагы елда уздырылган профилактик чаралар саны;
B – узган елда уздырылган профилактик чаралар саны.

2. *еллык күрсәткеч:* **төзекләндерү кагыйдәләрен бозганда, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан зыян салу фактларын киметү,%;**

V = (A / B –A1 /B1) x 100
A – узган елда төзелгән актлар (беркетмәләр) саны, берәмлек;
A1 – агымдагы елда төзелгән актлар (беркетмәләр) саны, берәмлек;
B – узган елда уздырылган планлы рейд караулары (систематик мониторинг) саны, берәмлек;
B1 –агымдагы елда уздырылган планлы рейд караулары (систематик мониторинг) саны, берәмлек;

3. *квартль күрситкеч:* **аларны томышка ашыру административ регламентлар кабул ителгән муниципаль контроль төрләре өлеше, муниципаль районда контроль төрләренең гомуми санынnan, %**

V= A/B x 100 %
A – кабул ителгән муниципаль контрольне тормышка ашыру административ регламентлары;
B – раланган муниципаль контроль төрләре